Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Колай авыл җирлеге Советының кырыгынчы утырышы

Колай авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

25 октябрь, 2024 ел № 112

«Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2019 елның 28 октябрендәге 55 номерлы Питрәч муниципаль районы Колай авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлеге нигезендә Питрәч муниципаль районы Колай авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

1. «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2019 елның 28 октябрендәге 55 номерлы Питрәч муниципаль районы Колай авыл җирлеге Советы карарына (2021 елның 22 мартындагы 18 номерлы карар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 пунктта:

а) 2.4 пунктчасын яңа редакциядә бәян итәргә:

«2.4. 2025 елда 1,2 процент; 2026 елда 1,2 процент; 2027 елда 1,2 процент; 2028 елда һәм аннан соңгы елларда түбәндәгеләргә карата 2 процент:

Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясындагы 7 пункты нигезендә билгеләнгән исемлеккә кертелгән салым салу объектларыны»;

Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясындагы 10 пунктының икенче абзацында каралган салым салу объектларыннан.»;

б) түбәндәге эчтәлекле 2.6 пунктча өстәргә:

«2.6. һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артып киткән салым салу объектларына карата 2,5 процент.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Питрәч муниципаль районы
Колай авыл җирлеге башлыгы Н.В.Поповская